Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге составына керүче Колмакчы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2022 елның 11 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 11 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Елантау авыл җирлеге Колмакчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме. Алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү:

- алынган акчаларны Центральная, Зеленая урамында юл салу өчен вак таш сатып алуга тотарга

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 204 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 128 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 128 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде, җыенда катнашкан 0 кеше "Тыелып торды" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге составына керүче Колмакчы торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбән Кама муниципаль районының Елантау авыл җирлеге Колмакчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме. Алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү:

- алынган акчаларны Центральная, Зеленая урамында юл салу өчен вак таш сатып алуга тотарга

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Елантау авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Елантау авыл җирлеге башлыгы В.А. Лебедев